СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

____________________ с. Сарманово №______________

22.05.2023 ел № 136

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон (2023 елның 14 апреленә үзгәрешләр белән), «Россия Федерациясенең аерым закон актларына (1 - 41 статьялар) үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 6.1нче пункты, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» Сарман муниципаль районы Советының 2016 елның 12 декабрендәге 55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 9 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) чит ил агенты статусы алу.»;

2) 1 не кушымтаның 10.2.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 бүлекнең 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район

Советы рәисе Ф. М. Хөснуллин